СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.09.2020 Әгерҗе шәһәре № 1-5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфасын биләүгә
конкурс игълан итү турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләре туктатылуга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының вәкаләтләре чоры тәмамлануга бәйле рәвештә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 48 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Контракт нигезендә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучылардан конкурска документларны кабул итү срогы итеп 2020 елның 26 сентябреннән 2020 елның 16 октябренә кадәр шул көнне кертеп 422230, Татарстан Республикасы, Әгерҗе ш., Гагарин ур., 13 йорт, 32 нче кабинет, «Администрация» бинасы адресы буенча эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр дип билгеләргә, контакт телефон/факс 8(85551) 2-17-53.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясенең гомуми санлы составын - 6 кеше итеп, аларның яртысын 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә:

- конкурс комиссиясенең гомуми санлы составыннан 3 кеше составында Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссияләре әгъзалары исемлеге вәкилләреннән тора, Татарстан

Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2014 елның 22 декабрендәге ПУ-1164 номерлы Указы белән расланган соңгы үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып);

- конкурс комиссиясенең гомуми санлы составыннан 3 кеше составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы вәкилләреннән тора.

4. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүне, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында» 29.05.2020 ел, № 47-4 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе таләпләренә туры китереп, түбәндәге адрес буенча үткәрүне тәэмин итә:: 422230, Татарстан Республикасы, Әгерҗе шәһәре, Гагарин ур., 13, «Администрация" бинасы, 2020 елның 27 октябренә кадәр срокта.

5. Конкурс комиссиясе конкурс нәтиҗәләрен һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатлар турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советына кертергә.

6. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт формасы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2020 елның 29 маендагы 47-4 номерлы карары белән расланган.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, вакытлы матбугат басмасында - “Әгерҗе хәбәрләре” газетасында бастырып чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Муниципаль район башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
«22» 09 2020 ел, №1-5
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссиясе
СОСТАВЫ

| Ф.И.О. | Эш урыны, вазыйфасы | Кем тарафыннан билгеләнгән |
|---|---|---|
| Вәлиев Азат Рөстәмович | Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы башлыгы | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы |
| Абзалиева Дания Зәңгировна | «Татмедиа» АҖ филиалы «Әгерҗе хәбәрләре» (Агрызские вести) газетасы редакциясе директоры-баш мөхәррире, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы иҗтимагый Советы әгъзасы | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы |
| Закирова Резида Әмировна | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы |
| 3 кеше | Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатуралар карау өчен конкурс комиссияләре әгъзалары исемлеге вәкилләре, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында» 2014 елның 22 декабрендәге ПУ-1164 номерлы Указы белән расланган соңгы үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып) | Килештерү буенча |